ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 474-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 474-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2188-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында»
Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына
үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Иҗтимагый палата» сүзләрен «1. Иҗтимагый палата» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 2 өлешне өстәргә:
«2. Иҗтимагый палата иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны каплый һәм аның эшчәнлеген матди-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүдә ярдәм күрсәтә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты 2022 елның 5 декабрендәге «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый контрольдә тоту турында һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган кешеләргә ярдәм итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 497-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Әлеге Федераль законның иҗтимагый күзәтү комиссияләре эшчәнлеген тәэмин итүгә кагылышлы 9 статьясы кертелгән үзгәрешләр белән төзәтелгән.

Россия Федерациясе субъектының иҗтимагый палатасына Россия Федерациясе субъектында оештырылган Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау, шулай ук аның эшчәнлеген матди-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү бурычын йөкләү карала.

Билгеләнгән нигезләмәне гамәлгә ашыру максатларында закон проекты белән «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына тиешле үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына**
**үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын**
**кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга,**
**туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле**
**Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итә.

Татарстан Республикасы бюджетының өстәмә акчаларына ихтыяҗ 1 154,0 мең сум күләмендә бәяләнә (бер елга исәпләгәндә), шулардан төп чараларны сатып алуга – 142,5 мең сум.

Бүгенге көндә иҗтимагый күзәтү комиссиясе Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына беркетелгән биналарда урнашкан, күрсәтелгән өлештә күрсәтелгән биналарны җәмәгать күзәтү комиссиясенә түләүсез куллану хокукында бирү күздә тотыла.